ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

01.11.2019 Алексеевск ш. т. б. № 67

“Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында “

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законы, «Коррупциягә каршы тору турында " 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы », «Вазыйфаи хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу турында аерым категория затларның хәбәр итүе, бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү тәртибе турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2014 елның 9 гыйнварындагы 10 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы, нигезендә

карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башкарма комитетының бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлеге баш белгечен

муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, вазыйфаи хәлләренә яисә хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә алынган бүләкләр белән эшне оештыру өчен җаваплы вазыйфаи зат итеп билгеләргә.

3. "Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында "Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2014 елның 31 мартындагы 22 номерлы карары.

"Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында Алексеевск муниципаль районы башлыгының 2019 елның 1 гыйнварындагы 8 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә веб-адрес буенча Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Район башлыгы вазыйфаларын башкаручы **Г. В. Белова**

Алексеевск муниципаль
районы башлыгы
01.11.2019 № 67карарына
кушымта

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турында

НИГЕЗЛӘМӘ

1. Әлеге нигезләмә Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм җирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибен билгели .

2. Әлеге Нигезләмәнең максатлары өчен түбәндәге төшенчәләр кулланыла::

муниципаль вазыйфаны биләүче зат-депутат, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты, даими нигездә эш итүче һәм юридик зат булган сайлау комиссиясе әгъзасы, даими (штат) нигездә комиссиядә эшләүче хәлиткеч тавыш хокукы белән, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының Контроль-хисап органы рәисе;

муниципаль хезмәткәр-федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә муниципаль хокукый актларда билгеләнгән тәртиптә, җирле үзидарә органында, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы сайлаулы комиссиясе аппаратында муниципаль хезмәт вазыйфасы буенча вазыйфаларны башкаручы, җирле бюджет акчалары исәбеннән түләнә торган хак алучы гражданин;

беркетмәле чараларга, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә алынган бүләк - муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан, муниципаль хезмәткәрләргә бирелә торган хезмәт (вазыйфаи) бурычларының вазифаи нигезләмәләреннән чыгып бүләк итүче физик (юридик) затлардан алынган бүләк, беркетмәле чаралар , хезмәт командировкалары һәм башка рәсми чаралар кысаларында күрсәтелгән чараларның һәр катнашучысына үзләренең хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәү максатларында бирелгән канцелярия кирәк-яраклары , чәчәкләр һәм бүләк сыйфатында тапшырылган кыймметле бүләкләр);

катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган беркетмәле чаралар, хезмәт командировкаларына һәм башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу - Муниципаль вазыйфаны биләүче затның, муниципаль хезмәткәрләргә шәхсән яисә физик (юридик) затлардан арадашчы аша вазыйфаи регламентта

(вазыйфаи инструкциядә) каралган эшчәнлекне гамәлгә ашыру кысаларында, шулай ук күрсәтелгән затларның хокукый хәле һәм һөнәри хезмәт эшчәнлеге үзенчәлекләрен билгеләүче Федераль законнарда һәм башка норматив актларда билгеләнгән очракларда хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле рәвештә бүләк алу.

3. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр, беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары, хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган башка рәсми чаралардан тыш, физик (юридик) затлардан бүләкләр алырга хокуклы түгел.

4. Муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм муниципаль хезмәткәрләр әлеге Нигезләмәдә каралган тәртиптә бүләк алуның барлык очраклары ,беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм катнашуы җирле үзидарә органының хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чаралар турында ,муниципаль хезмәт уза яисә хезмәт эшчәнлеген башкара торган Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы сайлаулы комиссиясенә(Алга таба-җирле үзидарә органы, сайлаулы комиссиясе) хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле булган башка рәсми чараларга хәбәр итәргә тиеш.

5 Беркетмәле чаралар, хезмәт командировкалары һәм катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын үтәүгә бәйле башка рәсми чараларга бәйле рәвештә бүләк алу турында , кушымта нигезендә төзелгән хәбәрнамә, муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан алынган бүләкләр белән эшне оештыру өчен җаваплы, вазыйфаи затка һәм муниципаль хезмәткәрләргә ,бүләк алынганнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Мөрәҗәгатькә бүләк бәясен раслаучы документлар (алар булганда) (касса чегы, товар чегы, бүләк өчен түләү (алу) турында башка документ) теркәлә.

Бүләк хезмәт командировкасы вакытында алынган очракта, ул бүләк алган затның хезмәт командировкасыннан кайтканнан соң 3 эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырыла.

Муниципаль вазыйфаны биләүче затка, муниципаль хезмәткәргә бәйле булмаган сәбәп аркасында әлеге пунктның беренче һәм икенче абзацларында күрсәтелгән срокларда хәбәрнамә бирү мөмкин булмаганда, ул аны бетергәннән соң икенче көннән дә соңга калмыйча тапшырыла.

6. Хәбәрнамә 2 нөсхәдә төзелә, аларның берсе теркәлү турындагы тамга белән мөрәҗәгать иткән затка кире кайтарыла, икенче нөсхәсе җирле үзидарә органы, бухгалтерлык исәбе турындагы законнар нигезендә төзелгән җирле үзидарәнең активлары керү һәм чыгару сайлаулы комиссиясенә (алга таба - комиссия)җибәрелә.

7. Бәясе документлар белән раслана торган, һәм хакы 3 мең сумнан артып китә торган бүләк , яисә муниципаль хезмәткәргә бәясе билгесез булган бүләк ,вәкаләтле вазыйфаи затка тапшырыла, ул аны теркәү журналында хәбәрнамәне теркәгән көннән алып 5 эш көненнән дә соңга калмыйча ,кабул итү акты белән,саклауга ала.

8. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат тарафыннан алынган бүләк, бәясе нинди булуга карамастан, әлеге Нигезләмәнең 7 пунктында каралган тәртиптә саклануга тапшырылырга тиеш.

9. Бүләкне кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырганчы, бүләкне югалткан яки зарарлаган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә бүләк алучы

җавап тота.

10. Бухгалтерия исәбенә бүләкне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә кабул итү максатларында, аның бәясен билгеләү бүләкне исәпкә алу датасына гамәлдәге базар бәясе яки, кирәк булганда, шундый ук матди кыйммәткә ия аналогик материаль байлык нигезендә үткәрелә. Базар бәясе турындагы мәгълүмат документаль, ә документаль раслау мөмкин булмаганда - эксперт юлы белән раслана. Бүләк, бәясе 3 мең сумнан артмаган очракта, аны кабул итү-тапшыру акты буенча тапшырган затка кире кайтарыла.

11. Вәкаләтле вазыйфаи зат билгеләнгән тәртиптә кабул ителгән бухгалтерлык исәбенә алынган бүләкне (бәясе 3 мең сумнан артып китсә) Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының муниципаль милек реестрына кертүне тәэмин итә.

12. Муниципаль вазыйфаны биләүче зат, бүләк тапшырган муниципаль хезмәткәр, аны яллаучы (эш бирүче) вәкиле исеменә тиешле гариза юллап, бүләк тапшырганнан соң ике айдан да соңга калмыйча сатып ала ала .

Җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе җитәкчесе, тиешле карар чыгарып, бүләк тапшырганнан соң ике айдан да соңга калмыйча, үзенә тапшырылган бүләкне сатып ала ала .

13. Вәкаләтле вазыйфаи зат әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза (күрсәтмә басылганнан соң) кергән көннән 3 ай эчендә сату (сатып алу) өчен бүләк бәясен бәяләүне оештыра һәм язма рәвештә гариза (боерык чыккан) биргән затка бәяләү нәтиҗәләре турында хәбәр итә, шуннан соң ай дәвамында мөрәҗәгать итүче бүләкне бәясен бәяләү нәтиҗәсендә билгеләнгән бәядән сатып ала яки сатып алудан баш тарта.

14. Әлеге Нигезләмәнең 12 пунктында күрсәтелгән гариза кермәгән(боерык чыгарылмаган) бүләк , җирле үзидарә органы, сайлау комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүләкне файдалануның максатка ярашлылыгы турында комиссия бәяләмәсен исәпкә алып, җирле үзидарә органы, сайлаулы комиссиясе тарафыннан кулланыла ала.

15. Бүләкне җирле үзидарә органы җитәкчесе, сайлаулы комиссиясе җитәкчесе файдалануның максатка яраксыз булганда, сатулар уздыру юлы белән муниципаль орган тарафыннан Россия Федерациясе законнарында каралган тәртиптә аның бәясен бәяләү һәм сату(сатып алу) үткәрү турында карар кабул ителә

16. Сату (сатып алу) бәясен бәяләү әлеге Нигезләмәнең 13 һәм 15 пунктларында каралган бәяләү эшчәнлеге субъектлары тарафыннан бәяләү эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнары нигезендә башкарыла.

17. Бүләк сатып алынмаган яки сатылмаган очракта, җирле үзидарә органы җитәкчесе, сайлау комиссиясе җитәкчесе тарафыннан бүләкне кабат сату яисә аны хәйрия оешмасы балансына түләүсез тапшыру турында, яисә аны Россия Федерациясе законнары нигезендә юк итү турында карар кабул ителә.

18. Бүләкне сатудан (сатып алудан) кергән акчалар Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджеты керемена Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә күчерелә.

Район Советының Аппарат җитәкчесе **А. С. Харитонов**

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районында, муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар һәм жирле үзидарә органнарында эшләүче муниципаль хезмәткәрләр тарафыннан, катнашу хезмәт (вазыйфаи) бурычларын башкару белән бәйле булган, беркетмәле чаралар вакытында, хезмәт командировкалары, һәм башка рәсми чаралар вакытында ,бүләк алу , бүләкне тапшыру һәм бәяләү, сату (сатып алу) һәм аны сатудан кергән акчаларны күчерү турында хәбәр итү тәртибе турындагы нигезләмәгә
Кушымта.

Бүләк алу турында белдерү

_____
(вәкаләтле вәкил исеме
_____
вазыйфаи зат)
кемнән _____
_____
(Ф. и. о., биләгән вазыйфасы)

Бүләк алу турында белдерү "___" _____ 20___ г.

Алыну турында хәбәр итәм_____ бүләк (- ов) _____
(алу датасы)
_____
(беркетмә чарасының исеме, Хезмәт командировкасының, башка рәсми чараның исеме, үткәрү урыны һәм датасы)

Бүләк исеме	Бүләкнең характеристикасы, аның тасвирламасы	Предметлар саны	хакы .сумнарда
1.			
2.			
h.б.			
Барлыгы:			

кушымта _____ _ _ _ _ _ _ _ _ .
(документның исеме)

Белдерүче зат
canlandıru _____ _____ "__" _____ 20__ г.
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)
Кабул иткән зат
canlandıru _____ _____ "__" _____ 20__ г.
(имза, дата) (имзаның аңлатмасы)

Гаризаларны теркәү журналында теркәү номеры _____
20___ елның «___» _____

<*> Бүләк бәясен раслаучы документлар булганда тутырыла.